ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ***

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***
***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ***

---

**КАРАР**

РЕШЕНИЕ

10.09.2026 № 1-18

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Советы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 11 февралендәге 5-7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы (28.12.2025 ред) Федераль законнар нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районыны Буа шәһәре Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Советы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 11 февралендәге 5-7 номерлы карарына ( 23.07.2021 № 2-11, от от 1 июня 2026 года № 1-14 ред) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының 2021 елның 11 февралендәге 5-7 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 5 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатка үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен эш бирүче тарафыннан эш урынын (вазыйфасын) саклап калып эшләүдән азат ителү, дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә торган һәм аена ике эш көненнән кимрәк һәм алты эш көненнән артыграк була алмаган чорга гарантияләнә.»

1.2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының 2021 елның 11 февралендәге 5-7 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 2 статьясындагы 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутат вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының (алга таба - Совет) тулы хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән туктатыла»
уздырган көннән туктатыла, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында әлеге Нигезләмәнең 4 статьясында каралган очраклардан тыш.»

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов